| СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2021 с. Сарманово № 49

**«2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына**
**Татарстан республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты турында»**
**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**Советы карары проектын кабул итү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты турында» карары проектын беренче укылышта кабул итәргә
2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.
3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты турында» карары проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:
- Габдулгазизов Илгизәр Габдулкаюм улы-төркем җитәкчесе;
- Мөхәммәдиева Азия Әсхәдулла кызы-төркем әгъзасы;
- Ризатдинов Габбас Гайнетдин улы-төркем әгъзасы;
- Нуруллин Рөстәм Рифгать улы-төркем әгъзасы;
- Хөсниева Вероника Вячеславовна-төркем әгъзасы;
- Билалова Алинә Инзар кызы-төркем әгъзасы.

4. Гражданнарның карар проектына тәкъдимнәре эш төркеменә, авторның Ф.И.О., туган елын, адресын күрсәтеп , ТР, Сарман ав., Ленин ур., 35 йорт, эл. почта: sarman@tatar.ru буенча язма рәвештә җибәрелә дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2021 елның 3 нче декабрендә 15.00 сәгатьтә район Советының утырышлар залында билгеләргә.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм карар проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен өйрәнергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советына 2021 елның 8 декабренә кадәр срокка кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Совет рәисе Ф. М. Хөснуллин